**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

« 07 » август 2024 ел № 10/5

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында, Тукай муниципаль районы бюджетына Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.3 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмә нигезендә Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында, Тукай муниципаль районы бюджетына Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне расларга (1 кушымта).
2. Әлеге карар 2024 елның 1 январеннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Утырышта рәислек итүче
Авыл җирлеге Советы
Тукай муниципаль районы
Татарстан Республикасы районнары,
6 нчы сайлау округы депутаты Д.З.Фазуллин

Совет
НИЖНЕСУЫКСИНСКОГО
сельского поселения
ИНН 1639009834

Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге Советының 2024 елның 07 августында 10/5 номерлы карарына 1 кушымта

# Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында, Тукай муниципаль районы бюджетына Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.3 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмә нигезендә кабул ителгән әлеге Нигезләмә белән, җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына (алга таба - Тукай муниципаль районы) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан (алга таба - Түбән Суыксу авыл җирлеге) субсидияләр (алга таба - субсидияләр) бирү тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

## 2. Субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары

2.1. Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль учреждениеләрне тотуга вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында бирелә.

2.2. Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты керемнәре хисабына башкарыла.

2.3. Тукай муниципаль районы бюджетына Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бюджет керемнәре классификациясе нигезендә Тукай муниципаль районы бюджетының керем өлешендә чагылыш таба.

2.4. Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына субсидияләр күләмен исәпләү әлеге Нигезләмәгә 1 кушымтага Методика нигезендә башкарыла.

2.5. Субсидияләр күләме Түбән Суыксу авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты турында карарында яисә Түбән Суыксу авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты турында карарына үзгәрешләр кертү һәм Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү юлы белән раслана.

2.6. Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына субсидияләр Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты турында карар белән чираттагы финанс елына һәм план чорына расланган сумма чикләрендә һәм Түбән Суыксу авыл җирлеге карары нигезендә бирелә.

2.7. Тукай муниципаль районы бюджетына Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр Түбән Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты арасында Түбән Суыксу авыл җирлеге карары нигезендә төзелгән килешүләр нигезендә (әлеге Нигезләмәгә 2 кушымта) бирелә.

2.8. Тукай муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү турында килешү түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

1) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;
2) субсидияләрне бирү һәм куллану шартлары;
3) субсидияләр бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;
4) субсидияләрне күчерү тәртибе;
5) субсидияләр бирү һәм сарыф итү өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен контрольдә тоту тәртибе;
7) финанс тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү вакыты һәм тәртибе;
8) башка шартлар.

2.9. Тукай муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү турында килешү проектын әзерләү Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты акчаларының баш бүлүчесе булып торган һәм субсидияләр күчерүне башкаручы Түбән Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

2.10. Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына субсидияләр Тукай муниципаль районы белән килешү төзелгәннән соң агымдагы елның һәр аеның 25 числосына кадәр ай саен бирелә.

2.11. Тукай муниципаль районы бюджетына Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр Тукай муниципаль районы бюджетының касса үтәлешен гамәлгә ашыручы органда ачылган бердәм счетына акча кертү юлы белән күчерелә.

2.12. Чираттагы финанс елының 1 январена кулланылмаган субсидияләр калдыклары буенча операцияләр (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясы 5 пункты нигезендә):

1) Агымдагы финанс елының 1 январена файдаланылмаган, Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына күчерелгән һәм максатчан билгеләнешле субсидияләр агымдагы елның беренче 15 эш көне эчендә Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты керемен кайтарылырга тиеш.

2) Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты акчаларының баш администраторы тарафыннан әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән, хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләргә ихтыяҗ булу (булмау) турында карар кабул итү, шулай ук аларга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, аларны Тукай муниципаль районы бюджетына кайтару, күрсәтелгән акчалар Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетына кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, килешү белән билгеләнгән тәртиптә һәм формада

формалаштырылган һәм тәкъдим ителгән, финанс тәэмин итү чыганагы булып әлеге субсидияләр торган Тукай муниципаль районы бюджеты чыгымнары турында хисап нигезендә гамәлгә ашырыла.

3) Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына күчерелгән һәм максатчан билгеләнешкә ия, финанс хисап елында кулланылмаган субсидияләргә ихтыяҗ булу турында Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты акчаларының баш администраторы карары нигезендә финанс органы белән билгеләнгән тәртиптә килешенгән, күрсәтелгән бюджетара трансфертларның калдыгыннан артмаган күләмдәге акчалар, агымдагы финанс елында Тукай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен, Тукай муниципаль районы бюджеты кеременә кайтарылырга мөмкин.

4) Әлеге пунктның 3 пунктчасында каралган карарлар кабул итү тәртибе җирле хакимиятнең җирле бюджетлардан бюджетара трансфертларны кайтару тәртибен көйләүче муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә.

5) Әгәр 1 январьга файдаланылмаган субсидияләр Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты кеременә күчерелмәсә, күрсәтелгән акчалар Россия Федерациясе Бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты керемено түләтелергә тиеш.

2.13. Түбәндәге очракларда субсидияләр Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетына кайтарылырга тиеш.

- аларны максатсыз куллануны ачыклау;
- Тукай муниципаль районы хисапларын тапшырмау;
- хисапта дөрес булмаган мәгълүматны күрсәтү.

2.14. Тукай муниципаль районы субсидияләрне ирекле тәртиптә кайтармаган очракта, күрсәтелгән акчалар Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетына закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә түләтелергә тиеш.

## 3. Субсидияләрне куллануны контрольдә тоту һәм исәпләү

3.1. Тукай муниципаль районының җирле үзидарә органнары Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан алынган субсидияләрне максатчан куллану һәм аларны куллану турында хисапларның дөреслеге өчен җаваплылыкка ия.

3.2. Субсидияләрне куллануны контрольдә тотуны Түбән Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитеты башкара.

3.3. Субсидияләрдән файдалану турында хисап Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм формада бирелә.

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында Тукай муниципаль районы бюджетына Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә 1 кушымта

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында, Тукай муниципаль районы бюджетына Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан бирелә торган субсидияләрне исәпләү методикасы

1. Әлеге Методика җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына (алга таба - Тукай муниципаль районы) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге (алга таба - Түбән Суыксу авыл җирлеге) бюджетыннан бирелә торган субсидияләрнең гомуми күләмен исәпләү өчен билгеләнгән.

2. Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль учреждениеләрне тотуга вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Тукай муниципаль районы бюджетына Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр күләме ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджеты проектын төзегәндә, Түбән Суыксу авыл җирлегенең гомуми ихтыяҗларын һәм керем мөмкинлекләрен бәяләүдәге аермаларга нигезләнеп билгеләнә.

3. Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль учреждениеләрне тотуга вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Тукай муниципаль районы бюджетына Түбән Суыксу авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = (Д1 + Д2)-(Р + С),$$

биредә:

S - Тукай муниципаль районы бюджетына җирлек бюджетыннан бирелә торган субсидия күләме;

Д1 - Россия Федерациясе бюджет законнарына, салымнар һәм җыемнар турында законнарга һәм башка мәҗбүри түләүләр турында законнар нигезендә беркетелгән җирлек керемнәре;

Д2 - Тукай муниципаль районыннан (Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына) торак пунктларның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр;

Р - Тукай муниципаль районының берләштерелгән бюджетын формалаштыруга бердәм төп алымнар нигезендә формалаштырылган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җирлек бюджеты чыгымнары;

С - Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә җирлек бюджетыннан Россия Федерациясе субъекты бюджетына күчерелергә тиешле субсидияләр.